ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе турында» 2005 елның 26 маендагы 1292-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 5; 2012, № 2, № 4, № 6 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (XI өлеш); 2018, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 48 (I өлеш) белән төзелгән Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) комиссия составыннан Ә.Г. Җәләлиеваны, Ш.Ш. Яһудинны чыгарырга;

2) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Баксиков Рәсим Рәшит улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасарын;

Степанов Алексей Федоровичны – Татарстан Республикасы пенсионерларның һәм инвалидларның – сәяси репрессияләр корбаннарының региональ иҗтимагый гуманитар оешмасы рәисен (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 166-VII ДС